Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең
Югары Акташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

29 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 29 ноябрь 11 сәгать 00 минутта, 2025 елның 29 ноябрь 14 сәгать 00 минутта булган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге Югары Акташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Югары Акташ авылы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (асфальтлаштыру, юлларга вак таш җәю)?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 570 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 302 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 302 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең Югары Акташ авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге Югары Акташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Югары Акташ авылы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (асфальтлаштыру, юлларга вак таш җәю)?” турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Югары Акташ авылы, Совет урамы, 15 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Акташ авыл җирлеге башлыгы А.В. Шатунов